# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

18 ноябрь 2022 ел                                                                 № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Усай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «2023 елда һәр балигъ булган гражданнан 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?", Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Усай торак пункты территориясендә теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү дә керә:

1) Усай авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Усай авылында өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар сатып алу;

4) МТЗ-82 тракторы өчен чапкыч сатып алу;

5) Усай авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

6) Усай авылында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

7) Усай авылында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны җыештыру һәм чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ                                                                 ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 61 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 33 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 33 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә.

2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Усай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2023 елда 700сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәүгә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

1) Усай авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Усай авылында өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар сатып алу;

4) МТЗ-82 тракторы өчен чапкыч сатып алу;

5) Усай авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

6) Усай авылында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

7) Усай авылында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны җыештыру һәм чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мэгълумат рэсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов